ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2021 Казан ш. № 488-146/кс-2021

«Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.11.2018 №10-90/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, эчә торган суга, ташландык су агызуга 2022-2023 елларга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай керменә төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыяте өчен 2019-2023 елларга эчә торган суга һәм ташландык суларны агызуга тарифлар билгеләү турында» 28.11.2018 № 10-90/кс карарының (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 №10-28/кс, 20.11.2020 №259-92/кс-2020 карарлары керткән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бирергә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы С.В. Павлов.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
28.11.2018 № 10-90/кс карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
10.12.2021 № 488-146/кс-2021 карары
редакциясендә) 1нче кушымта

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга 2019-2023 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Ташландык су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|---|
| | Алексеевск муниципаль районы | | | |
| 1 | «Алексеевскводоканал» ачык акционерлык җәмгыяте*, технологик яктан үзара бәйләнеше булмаган берничә үзәкләштерелгән система булуга карап, тарифларны дифференциацияләү: | | | |
| 1.1 | «Алексеевск шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге кулланучылары | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 30,19 | 37,80 |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 31,19 | 39,02 |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 31,19 | 39,02 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 32,19 | 39,93 |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 32,19 | 39,93 |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 33,46 | 41,51 |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 33,46 | 41,51 |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 34,81 | 48,40 |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 34,11 | 45,81 |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 34,11 | 45,81 |
| 1.2 | Биләр, Зур Полянка, Зур Тигәнәле, Бутлеровка, Войкино, Зирекле, Кыркүл, Көрнәле, Лебедино, Лебяжье, Левашево, Майна, Урманасты Шонталысы, Родники, Ромодан, Сахаровка, Кыр Шонталысы, Ялкын авыл җирлекләре кулланучылары | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 24,68 | |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 | 25,58 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кадәр | | |
| | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 25,58 | |
| | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 26,36 | |
| | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 26,36 | |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 27,41 | |
| | | 01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 27,41 | |
| | | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр | 28,86 | |
| | | 01.01.2023 башлап 30.06.2023 кадәр | 28,54 | |
| | | 01.07.2023 башлап 31.12.2023 кадәр | 28,54 | |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге